ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.04.2019 ел Баулы шәһәре №101

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне булдырмау һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында

Баулы муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне булдырмау һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы эшчәнлеген алга таба камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне булырмау һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында» 2004 елның 10 ноябрендәге 480нче номерлы карары (2018 елның 1 сентябрендәге редакциядә) нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

- Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне булдырмау һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында Нигезләмә (1нче кушымта);

- Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне булдырмау һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе турында Нигезләмә (2нче кушымта);

- Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне булдырмау һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе составы (3нче кушымта);

- Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне булдырмау һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы көчләре һәм даими әзерлек чаралары составы (4нче кушымта);

- Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында гадәттән тыш хәлләрне булдырмау һәм бетерү территориаль ярдәмче системасының эшләвен тәэмин итүче

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең Баулы муниципаль районындагы башкарма органнары һәм аларның функцияләре исемлеге (5нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне булдырмау һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының җирле звеносы турында” 2017 елның 26 маенда кабул ителгән 231нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров